СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №89 (7262) | 25 июль, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен

## Алда—янә Донсков

Колхоз комбайнчылары ярышына быел да тәҗрибәле механизатор Александр Егорович Донсков тон бирә. Ул үзенең ДОН-1500 комбайны белән 2875 центнер ашлык суктырды. Ярдәмче булып 4 ел инде аның улы Николай эшли. Донсковларның гаилә экипажы борчак, арыш суктыруда һәрчак алдынгы булды. Хәер, узган ел районның иң уңган игенчесе исемен яулаган кыр батырына бил бирү килешмәс дә иде әле. Юкса, ярышташлары да төшеп калганнардан түгелләр. Анатолий Еремеев, Николай Синдрякович Паруков (ул улы белән эшли) шулай ук таңнан төнгә кадәр фидакарь хезмәттә булалар, кыр уңганнарыннан саналалар. Игенчеләрнең кәефен күтәрерлек төп сәбәпләрнең берсе —кырларда әйбәт кенә уңыш үстерелгәнгә охшый. Әлегә ул уртача 23 центнер тәшкил итә. Ә 80 гектарлы арыш кырыннан уртача 29,5 центнер уңыш җыелды.

Игеннәрне теземнәргә салуда Николай Васильевич Кузнецов хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк. Ә ашлык ташуда Анатолий Владимирович Лизратов бик җитез.

Шундый бердәм хезмәт нәтиҗәсендә, хуҗалыкта арыш тезмнәргә салынып бетте, якын көннәрдә солы, арпа чабуга керешәчәкбез.

**В. ПАРУКОВ,**
«Большевик» колхозы партоешма секретаре.



Һәрнәрсәнең үз вакыты дигәндәй, игенчеләр бер эшне дә арткы планга куймаска тырышалар. Мәйданыннан игеннәре җыеп алынган кырларга хәзер салам тарттыручылар чыкты.

«Үрнәк» колхозы тракторчысы Гайса Мөнирович Шәраповны да бу көннәрдә ДТ-75 тракторы белән салам тарттырганда күрергә була. Ул тырыш хезмәте аркасында норманы 140—160 процентка үти.

Урак өсте башланганчы Гайса Мөнирович бульдозеры белән Тумба юлын күтәрүдә, колхозның машина-тракторлар паркында комбайннарны ремонтлау эшләрендә катнашты.

Һәр нәрсәгә кулы ятып торган, бөтен эшкә үрнәк бу кешене хезмәттәшләре дә яраталар һәм хөрмәт итәләр.

Рәсемдә: тракторчы Г.М. Шәрапов.

## Кыр эшләре ничек бара?

Беренче багана— хуҗалыклар исемнәре, икенче—уҗым культураларын, өченче— борчакны җыюның барышы (процентларда).
Мәгълүматлар 1991 елның 24 июленә.

| | | |
|---|---|---|
| Синдряков исем. | 100 | 86 |
| Ульянов исем. | 58 | 14 |
| «Правда» | 28 | 61 |
| «Восход» | 58 | 100 |
| Мичурин исем. | 84 | 77 |
| «Россия» | 100 | 100 |
| Хафизов исем. | 73 | 97 |
| «Путь к коммунизму» | 62 | 100 |
| Муса Җәлил исем. | 57 | 95 |
| «Родина» | 83 | 95 |
| «Игенче» | 68 | 91 |
| «Большевик» | 71 | 100 |
| «Заветы Ильича» | 81 | 44 |
| «Знамя Октября» | 62 | — |
| «Алга» | 50 | 100 |
| «Комбайн» | 51 | 100 |
| XXI партсъезд исем. | 54 | 100 |
| «Татарстан» | 85 | 100 |
| «40 лет Победы» | 60 | 29 |
| «Чишмә» | 60 | 100 |
| «Таң» | 95 | 100 |
| «Москва» | 50 | 100 |
| «Үрнәк» | 76 | 100 |
| «Лесная поляна» | 90 | — |
| «Кондырча» | 100 | 100 |
| Кузнецов исем. | 54 | 100 |
| «Заря» | 40 | 100 |
| «Чирмешән» | 40 | 66 |
| «Ленинский путь» | 61 | — |
| «1 нче Май» | 100 | 95 |
| «Тернос» совхозы | 10 | 100 |
| «Мамык» совхозы | 88 | 41 |
| «Рассвет» совхозы | 94 | 100 |
| «Сөлчә» совхозы | 55 | 25 |
| Хуҗалыкара берләшмә | 100 | — |
| «Яшь көч» | 55 | 67 |
| Район буенча | 62 | 78 |

## Соңгы гектарлар

«Рассвет» совхозы басуларында комбайннар шавы тәүлекнең берничә сәгатендә генә тынып тора. Механизаторлар борчак һәм арыш культураларын кыска срокта һәм сыйфатлы итеп җыеп алуга бар көчләрен куялар.

Совхоз буенча үстерелгән 886 гектарда арыш, 280 гектарда борчак теземнәргә салынып, соңгы гектарларда суктыру эшләре бара.

Минтаһир Фәйзуллин—136, Валерий Синцов—100, Минсәлих Төхфәтуллин—104 гектар мәйданда икмәкне кыска срокта тезмнәргә салып бетерделәр.

Ә Илсур Абдуллин—2500, Сәлих Бикиев—2300, Николай Гаврилов—1300, Фаиль Сатдаров 1250 центнер ашлык суктырып, үстерелгән икмәкнең бөртеген дә әрәм итмичә җыеп алуга бөтен тырышлыкларын куялар. Нурвахит Мәнапов, Зәки Габдуллин, Рәис Фәйзуллиннар да алардан калышмыйлар.

Шоферлардан Фәнис Сәйфуллин, Шамил Бикиев, Ирек Бәширов, Илдар Вәлитов басу-ындыр табагы конвейерында өзеклек тудырмыйча эшлиләр.

Ә кырдан кайткан икмәк ындыр табагында ышанычлы кулларга эләгә. Аны Марат Гайнуллин, Сәлих Галимов, Галимҗан Шәрипов, Якуб Сәләхетдинов кебек эшләрен белеп, җиренә җиткереп эшләүче машинистлар чистарталар да, сортларга да аералар, амбарларга да урнаштыралар.

**В. САТДАРОВ,**
экономист.

•*Безнең рейд*

## Амбардагысы икмәк

**Н.Октябрь элеваторы яңа уңышны кабул итә башлады.**

Ашлык төягән беренче олаулар шау-шусыз, бәйрәмсез генә кабул ителде быел, инде элеватор урак ритмына күчеп эшли башлады. Эш өч сменада оештырылды, үлчәү хуҗалыгы, лаборатория тоткарлыксыз эшли. Ашлыкны өзлексез кабул итү өчен бөтен шартлар бар. Әмма әлегә ул массовый төстә килә димәс идек.

—Көненә 500—600 тонна икмәк кабул итәбез, —диләр элеватор эшчеләре. —Көннәр әйбәт торганда, күбрәк килсә дә ярар иде...

Ә килгән кадәресе ни рәвешле җибәрелә—бусы сезон башында ук игътибар сорый торган нәрсә булып чыкты.

Быел район игенчеләре алдында моңарчы тормаган бурыч—он тарттыру промышленносте өчен чимал әзерләү, икенче төрле әйткәндә, 5100 тонна кыйммәтле һәм көчле сорт бодай тапшыру бурычы куелды. Мондый бодайның клейковинасы 18 проценттан да ким булмаска тиеш. Моның белән хуҗалыклар икеләтә кызыксынган булырга тиешләр, чөнки аның тоннасы 240 сум белән бәяләнә. Әмма беренче олаулардан күренгәнчә, аңа әлләни игътибар бирүләре күренми. Кузнецов исемендәге колхоздан 20 июльдә китерелгән бодайның клейковинасы 17 процент. 19 июльдә «Үрнәк»тән килгән бодайда да ул 16,8 процент. Күрәсез, бераз эшкәрткәндә— вак фракцияләрдән аралаганда, киптергәндә, бодайны нәкъ без әйткән кыйммәтле сорт белән тапшырып булыр иде. Әмма хуҗалыклар ни сәбәптәндер чималның сыйфат ягына аз игътибар бирәләр. Бу ашлыкның дымлылыгына да кагыла. «40 лет Победы», «Родина» колхозларыннан килгән икмәк 26—28 процент дымлылыкта иделәр. Базис дымлылыгының 15 процент булуын истә тотсак, әлеге хуҗалыкларның зачет авырлыгында күпме икмәкне югалтуларын чамалау авыр түгел. Һәм бу—быел, икмәкнең һәр бөртеге исәпле булырга тиешле елда! Ә бит нәкъ быелдан элеваторда ЦВ-3,3 дымлылыкны билгеләү приборы эшли. Ул бу процессны 1 минутта башкара. Хуҗалык белгечләре тапшырасы, орлыкка саласы ашлыкның дымлылыгын тиз генә билгеләтә алалар. Хафизов исемендәге, «Большевик» колхозлары моны шулай эшлиләр дә һәм ахыр чиктә югалтуларны булдырмау белән кызыксынган хуҗалыклар моны искә алмый калмаслар.

Элеваторга сортлы борчак керә башлады. Синдряков исемендәге, «Восход» колхозларын культурага опробацияләү актын, сорт удостоверениесен үз вакытында биргән һәм беренчеләр булып борчак сата башлаган өчен мактарга гына кала. Алар сорт өчен тиешле өстәмәне дә алачаклар. Башка колхозларга, совхозларга да опробацияләү актын тапшыруны сузмаска кирәк, чөнки алар бу очракта һәр тоннадан 150—200 сум акча югалтачаклар.

Быел авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең пошмаслыгы аркасында авылларда үлчәү хуҗалыкларын тәртипкә китерү соңарды: күп кенә колхозларда хәзергә хәтле үлчәүләрне кеэймәләү үткәрелмәгән, алар көйләнмәгән. Бу исә үз чиратында ашлыкны үлчәмичә җибәрүгә юл ача. «Знамя Октября», «Большевик», «Үрнәк», «40 лет Победы» колхозларыннан шулай ашлыкны үлчәмичә җибәрү очраклары күп. Ә «Знамя Октября», «Восход» колхозларыннан бөтенләй товар-транспорт накладноен тутырып тормыйча гына озатырга да курыкмаганнар. Бу югалтуурлаулар өчен турыдан-туры юл ачу түгелме икән? Икенчедән, элеватор мондый очракта транспорт хезмәтләре өчен түләмәскә дә хаклы. Ә бу чыгымнар аз җыелмый. Сирәк кенә булса да ашлыкны чыпта белән капламыйча озату очраклары да чыгып тора.

Болар һәммәсе хуҗалыклар белгечләренең, ындыр табагы эшчеләренең, шоферларның күз уңында булырга тиеш. Ашлыкның бөртеген дә сарыф итәргә ярамый. Чөнки кырдагысы түгел, амбардагысы гына икмәк әле аның. Ә амбарга җитүендә нәкъ алар җаваплы да.

**Н. ФОМИН,**
авыл хуҗалыгы продуктлары сату һәм сыйфат буенча баш дәүләт инспекторы.

**С. ХӘЙРУЛЛИНА,**
газета корреспонденты.

**Бүгенге санда**

*ИГЕНЧЕ ВАСУДА СЫНАТМАС.
*АШЛЫКНЫ, ӘРӘМ-ШӘРӘМ ИТМИК!
*КИЛӘЧӘК КҮРСӘТЕР.
*СӨТ МУЛЛЫГЫ ӨЧЕН.

## ХУҖАЛАР КАЯ КАРЫЙ?

Быелгы чорда районыбыз сөт җитештерү буенча алга китә алмады. Шуңа күрә халык хуҗалыгында кулланыла торган бу кыйммәтле продукциянең һәр килограммы исәптә. Җәйге дәвердә, сөт күбрәк чорда нәкъ шул алдагы айларда килгән югалтуларны бетерәсе иде дә бит. Әмма юк, шундый киеренке чорда да беришә хуҗалыклар тарафыннан сөт өстәмә югалтуларга дучар ителә. «Восход», «Знамя Октября», «Москва», «Большевик» колхозлары сөтне сөт-май комбинатына үлчәмичә һәм майлылыгын билгеләмичә китерәләр. Ә нәтиҗәсе куанычлы түгел: «Восход»ка—70, «Большевик»ка—105, «Знамя Октября»га—140, «Москва»га—70 сум штраф салынды. Югалтуларның күләме шул сумнар белән генә бәяләнми, әлбәттә. Хуҗасызлык, үз байлыгыңа салкын карaш, ягъни кыенлыклар белән җитештергән продукцияне саклык белән тиешле урынга китереп җиткермәү —хуҗалыкка да, гомумән, халыкка да зур зыян китерә.



## Яшьләр аңардан үрнәк ала

**Ул балачактан көтү көткән. Шунлыктан бу эшнең авырлыгын, җаваплылыгын үз җилкәсендә татыган. Хәзер исә Нургали Хәммәтгатович Сафин мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмәдә мактаулы эшчеләрдән санала. Ул интенсив юл белән үстерү группасындагы мөгезле эре терлекләрнең һәрберсеннән агымдагы елның алты аенда 697 шәр грамм уртача тәүлеклек үсеш алуга ирешә.**

**Нургали Хәммәтгатовичны коллективта да хөрмәт итәләр, яшьләр аңардан үрнәк алып эшлиләр.**

**Рәсемдә: мөгезле эре терлекләр симертү буенча хуҗалыкара берләшмә операторы Нургали Хәммәтгатович Әхмәтсафин.**

## Киләчәктән нәрсә көтәргә була

Бәяләрнең туктаусыз үсүе һәм апрельгә кадәрге запасларның әкренләп кими баруы кешеләрне хәзер җитди борчуга сала. Промышленность предприятиеләре эшчеләре, хезмәткәрләр бер уй белән янып яшиләр:

Гаиләне ничек туйдырырга да һәм яхшы заманаларга хәтле ничек түзәргә?

Дөрестән дә, киләчәк безгә нәрсә алып килер—стабильләштерү һәм тынычлыкмы, әллә тулысынча хәерчеләнү белән конфронтацияме? Гражданнар сугышы турындагы сөйләшүләр реаль рәвештә тормышка ашсалар?..

Бу яктан билгеләп үтәргә кирәк—илнең коммунистлары, барлык партия оешмалары бер урында таптаналар. Хәзергә хәтле нинди методлар белән, нинди юнәлештә эшләргә кирәклеге турында ачык ориентлашу булмады. КПССның программасы юк. КПССның республика оешмасы турындагы программасы да җитди эшләнеп бетмәгән. Әйтергә кирәк, район партия оешмаларында да аерым активлык һәм башлангычлар белән эшләгәндә эштә конкрет хәрәкәтләр сизелми. Шуңа күрә башлангыч оешмаларга, бигрәк тә түбән звеноларга тагын да авырга килә.

Аларга үзлектән эшләү мөмкинлеге бирелсә дә, аны ничек тормышка ашыру турында әлегә берни дә белмиләр. Күрсәтмәсез эшләргә өйрәнеп җитмәдек. Безгә инде бүгеннән үк алда торган политик вакыйгаларга карата әзер булырга кирәк. КПССның район комитеты да тезгенне әзрәк ычкындырды, башлангыч оешма секретарьлары белән күптәннән семинарлар һәм методик занятиеләр үткәрелмәде, ә бит секретарьларның составы 50 процентка яңарды. Һәм шунысы да бар, идеология эшенә тәҗрибәләре булмаган, башлап производствода эшләүче кешеләр килделәр.

Турыдан-туры политика белән бәйләнештә булган производство мәсьәләләренә дә кагылып үтәсе килә.

Һәммәгез дә яхшы беләсездер, материаллар, җиһазлар, запас частьләр җитешмәү һәм кисәк рәвештә аларның бәяләре күтәрелү аркасында эшләве аеруча кыенлашты. Татарстан суверенитет алгач, бу мәсьәләләр тагын да кискенләштеләр. Инде хәзердән үк Россия өлкәсенең һәм башка регионнарның республиканы экономик яктан кысулары турында сүзләр йөри. Турыдан-туры сорау туа: суверенитет игълан итеп ялгышмадык микән? Сорау, әйтергә кирәк, законлы рәвештә бирелә. Чөнки бу хакта халыктан сорамадылар, алар белән халык депутатлары киңәшмәделәр. Биредә яңадан безне, коммунистларны гаепләргә маташырлар.

Кешеләр үзгәрде. Үткәннәргә алар башка күзлектән чыгып карыйлар, үз предприятиеләрендәге уңышларда тормыш шартлары яхшыруны гарантиялиләр. Базар тау артында түгел, хәзергә безне ул куркыта гына. Менә шуңа күрә дә безнең районның барлык коммунистларын, эре предприятие җитәкчесе яки эшче булсынмы, бердәм булып, халыкның тормыш шартларын абстракт рәвештә генә түгел, ә һәрбер кешенең тормыш-көнкүрешен аерым яхшыртуга юнәлдерерлек итеп булышуда күрәсе килә.

**Л. ТАХТАМАНОВ,**
«Норлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе.

# Тарихка күз салсак

Элек тә шундый хәлләр булган: тарихның текә борылышларында, кискенләшә барган социаль һәм сәяси кризис шартларында партиядә бара торган процесслар нәтиҗәсендә төрле очраклы элементлар, юлдашлар, куркак җаннар өскә калыкты.

Россиядәге беренче революция (1905—1907) җиңелгәннән соң килгән реакция елларын искә төшерик. Ул елларда РСДРП ның рәтләре сизелерлек сирәгәйгән иде, күпләрне җиңелү кәефе биләп алды. Партиядән качып, алар аның калган өлеше—сәламәт үзәгенә каршы аяусыз көрәш башладылар.

Һәм 1917 елның июль вакыйгаларыннан соң РСДРП(б)ның кайбер әгъзалары контрреволюция басымыннан соң югалып калдылар, партиядән чыктылар. Ә инде Октябрь революциясеннән соң Ленин инициативасы белән НЭПка күчү башлангач, күп кенә коммунистлар яңа икътисади сәясәтнең асылын аңлап тормастан, протест йөзеннән РКП(б) сафларыннан чыктылар.

Төрле тарихи этапта, төрле шартлар хәрәкәт итсәләр дә, монда бер закончалык күзәтелә. Партияне күбрәк өлгереп бетмәгән, ныклы инанганлыгы булмаган кешеләр ташлады. Ә бу һәрвакыт кризислы ситуацияләр һәм сәяси каршылыклар кискенләшү белән бергә барды.

Безнең җәмгыять бүгенге көндә нәкъ шундый чор кичерә. Үзгәртеп кору процесслары партиягә дә авыр тәэсир итә. Шундый сорау туа: башлангыч партия оешмаларына мондый шартларда эшне ничек оештырырга соң?

Минемчә, үткәннәр тәҗрибәсенә таянып, Ленин сүзләре белән әйтсәң «массаларны үзеңә карату». Ничек? Әйдәгез, бергәләп уйлашыйк.

Үткән елда, мәсәлән, 1 нче июльгә 23 баланың суга батып үлү очрагы теркәлгән иде. Быелның бүгенге көненә инде 50, шуның 10 очрагы безнең районда.

Махсус кызыну, балалар һәм зурлар өчен дә су буйларында ял итү урыннарының булмавы хаклы рәвештә район халкының ачуын кабарта. Ә мәктәп яшендәге 70 процент бала суда йөзә белми.

Районыбыздагы 4000 куб. метр егәрлекле 28 артезиан коесы булып, шуның 80 проценты предприятиеләрнең техник хаҗәтләренә тотыла. Эчә торган суга кытлык менә шулай туа.

Яшьләрнең буш вакыты проблемалары.

Минем карашка, коммунист-депутатлар шушы якында торган бурычларны хәл итүгә керткән өлешләре турында җирле радио һәм район газетасы аша халыкка даими хәбәр итеп торсалар, бу башлангыч партия оешмалары авторитетын күтәрүдә бер чара булыр иде. Һәм шундый коммунистлар —халык депутатлыгына кандидатлар сайлау комиссиясендә күбрәк тавыш җыя алырлар иде.

Тормыш өчен бик әһәмиятле булган шушы бурычларны хәл итүдә башлангыч партия оешмаларының иң алгы сафта булулары, халык ихтыяҗлары турында ясалма түгел, бәлки чын кайгыртучанлык күрсәтүләре сорала. Шул гына аларның ролен күтәрә ала.

Ә чынбарлыкта бүгенге көнгә без нәрсә күрәбез?! Мәсәлән, шул ук су буенча. 4 апрельдә бу хаҗәттән махсус техник киңәшмә булды. Аның документларында шәһәрне су белән тәэмин итү өстендә эшләүче конкрет предприятие, оешма, җитәкче коммунистлар исеме күрсәтелгән. Аннан соң 3 айдан артык вакыт узып бара, ә конкрет нәрсә эшләнде соң?

Менә шуннан коммунистларның эшчәнлекләренә нәтиҗә ясала да инде. Бу турыда онытмасак иде.

Партия авторитетын торгызуда эше белән керткән өлеше турында һәр җитәкче-коммунисттан катгый рәвештә таләп итү зарур.

Таләпчәнлек һәм битарафлык белән килешмәүчәнлек шартларында гына уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин булачак.

**Х. ГАФУРОВ.**

## Ветераннар советы эштә

«Рассвет» совхозы ветераннар советы үзенең соңгы утырышында урып-җыю чорында колхозга булышу мәсьәләсен карады. Без былтыргы урак өстендә дә игеннәрне урып-җыюга үзебезнең хәлдән килгәнчә булышкан идек. Күбебез ындыр табагында ашлык чистарту белән шөгыльләндек. К. Гобәйдуллин, Г. Бикметов, И. Сатдаров әйбәт эшләделәр. Безнең пенсия яшендәге картларның күбесе даими эштә йөри.

Әле быел Кондырча елгасы аша күпер салуны да ветераннар үз өсләренә алдылар. Бу күпер авыл халкы өчен бик кирәк. Чөнки аннан сыер көтүе аръякка чыгып йөри. Бу эшне алып бару өчен совхоз дирекциясе кирәк-яракны бирә. Ә инде әрәтеп ябыштыру, балта эшләрен үзебез башкарабыз.

Авылда төзелеш эшләре киң колач алды. Яңа мәчет төзелә. Аны төзүдә Ш. Гозәеров, К. Гобәйдуллин, У. Гайнуллин, Г. Бикметов һәм башкалар актив катнаша.

Әнә шулай сугыш һәм хезмәт ветераннары бер эштән дә читтә калмыйлар.

**Т. ГОБӘЙДУЛЛИН,**
«Рассвет» совхозының ветераннар советы председателе.

## Столыпин: тормыш һәм үлем

САРАТОВ. «Столыпин: тормышы һәм үлеме»—шушы исем белән Идел буе китап нәшриятында җыентык әзерләнә. Аңа Петр Аркадьевич Столыпин турындагы Нью-Йоркта басылып чыккан китаптан материаллар, совет авторлары мәкаләләре, Столыпиннар гаиләсе архивыннан сирәк фотографияләр һәм башка материаллар керә.



Россия тарихындагы трагик фигураларның берсе П.А. Столыпин (1862—1911)—үзенә киңрәк игътибарны тарта бара. Элекке Саратов губернаторы, аннан соң эчке эшләр министры, министрлар Советы рәисе, күрелмәгән тизлектә илне омтылышлы игътисади күтәрелешкә китергән, аның турында бетен җирдә сөйләгәннәр.

Рәсемдә: П.А. Столыпин 1910 елда Мәскәү янындагы хутор хуҗалыгын караганда крестьяннар белән сөйләшә.

## Хезмәтләрен хөрмәтләп

Хезмәтияләренә иҗтимагый--политик тәрбия бирү эшендә актив катнашканы, «Дуслык» район газетасына 60 ел тулу уңае белән русча тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасары Гөлфирә Мөбәрәкшовна ХӘЛИУЛЛИНА халык депутатларының Октябрь район Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

x x x

Хезмәт ияләренә иҗтимагый-политик тәрбия бирү эшендә актив катнашканы, «Дуслык» район газетасына 60 ел тулу уңае белән җаваплы секретарьның чувашчага тәрҗемә буенча секретарь урынбасары Зоя Ивановна ЯЛЛИНА халык депутатларының Октябрь район Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## ТУГАН ИЛ БУЙЛАП

СИМФЕРОПОЛЬ. Белгечләр раславынча, Кырым басуларында һәм бакчаларында өлгергән уңышны җыеп алу өчен 25 мең пар кул кирәк. Әмма быел шәһәр кешеләре хуҗалыкларга ярдәмгә өстән кушу белән түгел, үз теләкләре буенча баралар: колхозлар һәм совхозлар кешеләр белән контрактлар төзи.

ВЛАДИКАВКАЗ. Төньяк Осетия хуҗалыкларында уҗым бодаен ура башладылар. Өч район басуларында контроль суктырулардан күренгәнчә, гектардан 30 центнер уңыш чыгар дип көтелә. Көчле эсселәр торучы дала хуҗалыкларында уҗым культуралары урылып бетте инде. Уртача республика буенча гектардан 35 центнер уңыш алыныр кебек.

(ТАСС).

## ИШЕТТЕГЕЗМЕ ӘЛЕ..

Идел буе—Урал хәрби округы частьларының берсендә коточкыч фаҗига булды.

Төнге өченче яртыда каравылда торучы ике хәрби хезмәткәр йоклап яткан хезмәттәшләренә ата башлыйлар. Бер гаепсез 9 кеше һәлак була. Авыр яралылар бар. Аларның берсе иртәнгә үлде.

Җинаятьчеләр ике автомат һәм 600гә якын патрон алып качканнар.

